ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№1051 от «11»09 2017 г.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районында
2017-2018 елларның көзге – кышкы җылыту
чорын башлау турында

Тышкы һаваның уртача тәүлеклек температурасы муниципаль учреждениеләрдән кышкы режимда файдаланырга мөмкинлек бирә торган булып торыклануы сәбәпле, “Җылылык белән тәэмин итү турында" 27.07.2010 ел, № 190-ФЗ Федераль закон, Россия Энергетика министрлыгының 12.03.2013 № 103 "Ягу чорына әзерлекне бәяләү кагыйдәләрен раслау турында"12.03.2013, № 103 карары нигезендә, Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты турындагы Нигезләмәгә таянып, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. Мамадыш муниципаль районында җылыту сезоны 2017 елның 15 сентябреннән башлана дип билгеләргә.

2. ААҖ “Мамадыш җылылык челтәрләренә” (Миннахметов Р.Р.) җылыту чоры башланганчы гомуми белем бирү, мәктәпкәчә учреждениеләр, сәламәтлек саклау, социаль яклау, мәдәният, физик культура һәм спорт учреждениеләренә җылылык җибәрүне сынап карарга.

3. ААҖ “Мамадыш җылылык челтәрләренә” (Миннахметов Р.Р.) үз балансында котельныйлары булган авыл җирлекләре башлыкларына, предприятие һәм учреждение җитәкчеләренә, җылыту сезоны башлану белән бәйле кирәкле чараларны башкарырга һәм җылылык энергиясе бирүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Р. К. Мөхәммәтҗановка йөкләргә.

Җитәкче И.Э.Фәттахов